**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ**

422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОН СОВЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**27 гыйнвар 2023ел** **№ 166**

**Әтнә муниципаль районы Советының «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Әтнә муниципаль районының бюджеты турында»гы 2022 елның 15 декабрендәге 159 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Әтнә муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе Ф.И.Гыймадиев докладын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң Әтнә район Советы карар чыгарды:

1). 1нче һәм 4нче статьяларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1 Статья

1. 2023 елга Әтнә муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын расларга:

а) Әтнә муниципаль районы бюджетының фаразланыла торган гомуми керем күләме 562002,7 мең сум.;

б) Әтнә муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 565844,0 мең сум.;

в) Әтнә муниципаль районы бюджеты кытлыгы 3841,3 мең сум.

2. 2023 елга Әтнә муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә расларга.

4 Статья

1. 2023 елга бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм төрләре буенча Әтнә районы бюджет ассигнованиеләренең бүленешен әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә үзгәртергә.

2. 2023 елга Әтнә муниципаль районы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Әтнә муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен Әтнә муниципаль районының бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (муниципаль программалар һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), 2022 елга бюджет чыгымнары классификациясенең чыгымнар төрләре төркемнәре буенча әлеге Карарга 5 нче кушымта нигезендә бүлүне расларга.

2). Әтнә районы Башкарма комитетының «Өстәмә акча бүлеп бирү турында»гы карарын расларга: № 54 от 27.01.2023г.

3). Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының www.atnya.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы www.pravo.tatarstan.ru хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

Әтнә муниципаль районы башлыгы –
Әтнә район Советы рәисе Г.Г. Хәкимов